**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

№ 101 «23» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 13 июнендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Туймәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 13 июнендәге №84 ТР Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

4) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге №229-ФЗ Федераль законның 46 һәм 47 статьяларының 1 өлешендәге 3,4 пунктларына ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы тарафыннан карар чыгару;

5) салым түләүче физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы (өлкәннәр, инвалидлар, яшь инвалидлар, инвалид балалар, сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен интернат - йортларда;

- интернат-йортларда, шул исәптән психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар йортларында;

- махсус интернат-йортларда, шул исәптән картлар һәм башкалар өчен) җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә;

6) ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютта тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затлар;

7) җирле үзидарә органнарының раслаучы документлары булган очракта аз керемле физик затлар;

8) психик тайпылышлары булган, суд карары яки җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танылган физик затлар;

9) ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган физик затлар, суд карары нигезендә ирektән мәхрүм итү урыннарында булу чорына.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Б. Кәримов